# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**“06” апрель 2024 ел, № 8**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Түбән Пошалым авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Түбән Пошалым авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Түбән Пошалым авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Түбән Пошалым авылында гражданнар җыенының 2024 елның 06 апрелендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре яңа редакция белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Түбән Пошалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 305 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 610 сум күләмендә үзара салым кертү шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү, Пионер урамындагы 30 нчы йорт янындагы канауны вак таш белән тутыру, торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту);
- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү(агачларны санитар кисү һәм зират территориясеннән чыгару)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены нәтиҗәләре беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 172 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар

саны 92 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 92 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Түбән Пошалым авылында халык җыены булып узган, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.Халык җыены нәтиҗәләре соравын яңа редакциядә кабул итәргә:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Түбән Пшалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 305 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 610 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү, Пионер урамындагы 30 нчы йорт янындагы канауны вак таш белән тутыру, торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту);

- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү (агачларны санитар кисү һәм зират территориясеннән чыгару)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә, карар кабул ителгән дип танырга».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Арча районы, Түбән Пошалым авылы, Пионер урамы, 22А йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan. ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков